# Мәктәп хәбәрчесе

№8 (№11) октябрь 2019 ел

Түбән Майна урта мәктәбе гәзите

Тел. 8 (84344) 4-38-46 sch1644maina@mail.ru


**/Өлкәннәр киңәше /**

## Мәктәп милкенә сакчыл карыйк

МӘКТӘП укучы тормышында нинди урын били? Әлбәттә мәктәп, беренче чиратта, балаларны уйларга, укырга, язарга, санарга, аларны сәнгатькә өйрәтә торган уку йорты. Биредә халыкның күп гасырлар буена тупланган мәдәни мирасы саклана. Шул сәбәпле мәктәп авылның рухи үзәге булып тора. Без мәктәпкә һәр көнне, ял көннәреннән тыш, күп еллар дәвамында киләбез. Биредә без хезмәт итәбез, укытучылардан белем һәм тәрбия алабыз, күңелебезгә охшаган һөнәр сайлыйбыз... Биредә гомер буе искә алырлык укытучыларыбыз, дусларыбыз, иптәшләребез.

Шул ук вакытта, мәктәп – ул укытучылар һәм классташлар гына түгел: бу уңайлы сыйныфлар да, бизәлгән иркен коридорлар да, уен һәм спорт мәйданчыклары, агачлар, чәчәкләр белән бизәлгән ишегалды да... Икенче төрле әйткәндә, болар барысы да рухи үзәкнең матди тышчасы. Мәктәп бинасы һәм анда булган һәр нәрсә барыбызның да уртак милке булып тора. Биредә эшләүче һәркем – укучылар, укытучылар һәм хезмәткәрләр – әлеге милектән файдалана. Менә шул күп кеше файдалана торган әйберләргә безнең карашны үзгәртәсе иде, чөнки алардан киләсе буын балалар да файда күрергә тиеш.

Кызганычка каршы безнең мәктәптә дә бу мәсьәлә көн кадагында тора. Бозылган диварлар, ватылган пыяла, буялган парталар, ишеге каерылган шкафлар, ертылган туплар, тапталган түтәлләр... Санап китсәң тагын дәвам итәргә була. Бу читтән килгән балалар эше түгел, шул мәктәп укучылары “хезмәте”. Шулай дәвам ителсә, яңа киләсе укучыларга нинди мәктәп бүлмәләре калачагын күз алдына китерүе кыен түгел. Һәрбер җиһаз бәяле, аларны яңарту күп чыгымнар сорый. “Җыйган җирдә чиста түгел, чүпләмәгән җирдә чисталык” ди халык мәкале. Кемдер мәктәп милкенә ялгышлык белән зыян салса, үз хатасын танып, китергән зыянны капларга тиеш. Үз гамәлләрең өчен җавап бирә белү чын егетлек һәм өлгергән шәхес сыйфаты булып тора.

Мәктәп еллары тиз үтә, шул арада ныклы белем алырга, тәрбияле булырга өйрәнергә, җәмгыятькә файда китерә торган шәхес булып формалашырга кирәк. Киләчәктә мәктәп еллары безнең күңелләрдә уңай хатирәләр белән истә калырлык итеп, үзебезнең шәхси әйберләргә дә, җәмәгать милкенә карата да мөнәсәбәтне уңай якка үзгәртсәк иде. Әти-әниләр, сез дә бу эштән читтә калмасагыз, безнең уртак бурыч булган тәрбиябез тиешле дәрәҗәдә булыр.

***Рифгать Туктамышев, химия-биология укытучысы***

## 5 октябрь – Укытучылар көне




Җир йөзендә һөнәрләрнең яңасы һәрвакыт барлыкка килә тора, ихтыяҗлар да үзгәрә тора. Ләкин кайбер һөнәрләр үзләренең кыйммәтен югалтмыйча бүгенге көндә дә кирәкле, мөһим булып кала бирә.

Сүзем укытучы һөнәре турында. Үз исеменә матурлыкны, яхшылыкны да, кайгыртучанлыкны да, шул ук вакытта таләпчәнлек белән бераз усаллыкны да туплаган һөнәр иясе ул. Укучыларына һәрвакыт игътибарлы, алар өчен вакытын да, көчен дә кызганмаска, чөнки каршыңа килгән һәр укучыга яратуны да, белемне дә тигез өләшергә кирәк.

Укытучым! Сезгә сәламәтлек, гаилә иминлеге, сабырлык, тырыш укучылар телибез. Сайлаган эшегез һәрвакыт шатлык кына китерсен иде. Яраткан укучыларыгыз янында Сезне һәрвакыт сау-сәламәт, елмайган, нурлы итеп күрсәк иде.

***“Мәктәп хәбәрчесе” редколлегиясе***

**/Рәсми хәбәрләр**

## I чирек нәтиҗәләре

29 октябрьдә 2019/2020 уку елының беренче чиреге тәмамланды. Мәктәптәге 55 укучының 41 енә чирек билгеләре чыгарылды. II сыйныфтан Закирова Ләйсән белән III сыйныф укучысы Гафиятуллин Фаил чирекне гел “5” ле билгеләренә, ә 23 укучыга “4”ле,”5”ле билгеләре чыгарылды. Шулай итеп, беренче чирек нәтиҗәләре буенча, укучыларның белем сыйфаты 61% тәшкил итте. Бу чиректә дәрестән тыш чаралардан Белем бәйрәме, Тәрбиячеләр, Өлкәннәр һәм Укытучылар көне билгеләп үтелде. Уңыш бәйрәме чирек ахырында уздырылды.

***Укыту-тәрбия эшләре буенча директор урынбасары И.Х.Сафиуллин***




## Үзидарә көне

Укытучыларның һөнәри бәйрәме мәктәбебездә ел саен үзидарә көне итеп билгеләп үтелә. Бу көнне югары сыйныф укучылары үзләре сайлап алган фәннәрне укытырга тиеш булалар. Быел искәрмә булмады. Кемдер башлангыч сыйныфларда, кемдер урта һәм югары сыйныфларда көчен һәм белемен сынады.

Башлангыч сыйныфларны 10 сыйныфтан Залиева Илдеяр белән Шәрифуллин Илсаф, физика дәресләрен Морадимов Илназ, географияне Шәфиков Әнис алып барды, 11 сыйныфтан Сафиуллина Динә инглиз телен, Камалова Гүзәл татар телен, Гыйльметдинова Әлфинә математиканы үткәрде. Эшләренә җаваплы һәм җитди карап алларына куелган максатны башкарып чыктылар. Укытучы роленә кереп, укучыларыбыз беренче сынауларны үткәндә әлеге һөнәрнең авыр икәнен, балаларга белем бирү сабырлык һәм түземлек соравын аңладылар.

***Зөлфирә Сафиуллина, 8 нче сыйныф укучысы.***

## Мәктәптә “Уңыш бәйрәме”



Мәктәптә һәрбер чирек безнең өчен кызыклы чара, я бер бәйрәм белән тәмамлана. Беренче чирек, әлбәттә, Көзге бал белән истә кала. Бу бәйрәмне без генә түгел, читтә укыган студентлар да, әти-әниләр дә, авылдашлар да көтеп ала. Көзге муллык бәйрәмен иң элек балалар бакчасы башлап җибәрде. Быел әниләр “Башак” әкиятен сәхнәләштерделәр. Балалар да оста итеп чыгыш ясаганнан соң, бәйрәм рухы өстәл артында да дәвам итте.

Башлангыч сыйныфлар елдагыча мавыктыргыч итеп, әти-әниләр белән берлектә үткәрде. Өстәлдә балалар кулыннан ясалган “Көзге муллык” дип аталган сувенирлар күргәзмәсе оештырылып куелган иде. Иң элек бу ел фасылының матурлыгы, икмәк кадеренә хөрмәт тәрбияләү турында монтаж күрсәтелде. Кызлар арасында ярышта берсеннән-берсе оста булган “Сөмбелә”не сайладылар. Тик әниләр хөкеме белән һәрбер катнашучы җиңүче дип танылды. Үзебезнең бакча нигъмәтләреннән мул итеп өстәл дә әзерләгәннәр иде.

Урта һәм югары сыйныфлар өчен иң көтелгән КВН киче беркемне битараф калдырмый. Биючегә сүз әйтмәгез,бии бии остара дигәндәй, укучылар ел саен үткән елга караганда сәләтлерәк була бара. Ике командага бүленгән укучылар үзләренә бирелгән биремнәрне бик тырышып, максат куеп үтәделәр. Беркемнең дә артта каласы килми! Алар 7 төрле биремне берсеннән-берсе остарак итеп башкардылар. Командалар биремнәргә әзерләнгән арада урта сыйныф укучылары җыр, бию белән тамашачыларны ял иттерделәр.

Бәйрәм шундый күңелле хәтирәләр калдырды, үзебезнең тырыш һәм кумәк көч белән әзерләнгән тамаша әти-әниләребезне дә, укытучыларны да канәгать калдырды.

***Самат Гафиятуллин. 6 сыйныф укучысы***



## 20 октябрь – Пешекчеләр көне

Безнең мәктәптә Укытучылар көне белән беррәттән, Тәрбиячеләр һәм Пешекчеләр көннәрен зурлап билгеләп үтү гадәткә кереп бара. Быел барыбызны да тәмле ашлары белән сыйлаучы **Айгөл һәм Илсөяр апаларны** котларга бакча төркеме балалары бик ныклап әзерләнгәннәр. Алар пешекче апаларына бәйрәм тамашасы күрсәтеп кенә калмыйча, стена газетасы да чыгарганнар. Без хәзер эшләүче **Илсөяр, Айгөл һәм Нәзимә апаларны,** элеккеге елларда әлеге мактаулы хезмәтне башкарган **Мөнибә һәм Әкълимә әбиләрне, Миңлегөл, Гөлсинә, Рәмзия, Роза, Рәмия апаларны** да чын күңелдән һөнәри бәйрәмнәре белән котлыйбыз. Киләчәктә дә безне тәмле ашларыгыз белән шатландырып эшләгез!

***Барча укучылар һәм тәрбияләнүчеләр исеменнән “Мәктәп хәбәрчесе” редколлегиясе***

## Авылыбызның беренче математигы

Газетабызның һәр санында авылыбызның ихтирамга лаек шәхесләре турында мәкаләләр бирергә тырышабыз. Бу язмабыз тормышын яшь буынга белем бирүгә багышлаган, фидакарь хезмәте белән халык ихтирамын казанып, укучыларыннан бүгенге көндә дә җылы хатирәләр ишетерлек эз калдырган мәгариф ветераны Вәлиәхмәт абый Нигъмәтуллин турында. Без бу шәхескә кагылышлы сораулар белән хәзерге вакытта авылда гомер кичерүче улы Венер абый белән аның тормыш иптәше Флера апага мөрәҗәгать иттек.

**- Венер абый, әтиегез Вәлиәхмәт бабай турында сөйләп үтсәгез иде.**

- Әти 1907 елда шушы авылда дөньяга килә. Башлангыч белемне авыл мәктәбендә ала. Сугыш елларындагы авыр хәлләрне дә үз башыннан кичерә. Мари республикасындагы Суслонгерь лагеренда булганнан соң, бик авыр хәлдә авылга кайта. Шул авырулардан терелгәч, укытучылыкка институтта укырга керә.

**- Әтиегез нинди фәннәрне үзләштерә?**

- Әти математика укытучысына укый. Гомере буена математика укытып, шул фәнгә бирелеп эшләде.

**- Әтиегез хезмәт юлын нинди мәктәптән башлый?**

- Ул Әлки районы Чуаш Кичүе авылында хезмәт юлын башлап җибәрә. Икенче эшләгән урыны Колбай Мораса авылы мәктәбендә булды. Аннан соң Югары Майна җидееллык мәктәбендә лаеклы ялга чыкканчыга кадәр эшләде. Әтинең шактый гомере шул авылда узды. 1950 еллар уртасында гына Түбән Майнада йорт салып, Югары Майна мәктәбенә йөреп эшләде.

**- Флера апа, Сез Вәлиәхмәт бабайның укучысы булганыгызны әйттегез. Аның эшчәнлеге турында нинди истәлекләр саклыйсыз?**

- Мин Югары Майна мәктәбендә укыдым. Әти эшенә, үз фәненә бик нык бирелгән укытучы иде. Математиканы бик белеп, җиңел, гади, аңлаешлы телдә аңлатып бирүче укытучы иде ул. Безне, туган авылы балаларын, бик тә якын итеп эшләде. Юешләнеп килгән көннәрдә, киемнәребезне киптерер өчен, ягылган мич янына берничә рәт җеп элеп бирде. Үз әтиебез кебек кайгыртып, киемнәребезнең корысына алмаштыруларыбызны карап, барлап тора иде.

**- Димәк, сезнең чор укучылары Вәлиәхмәт абыйны нәкъ шулай искә алалардыр.**

- Әлбәттә, шулай. Укытучының укучылары өчен фидакарь хезмәте дә, аның җылы мөнәсәбәте дә онытылмый. Бу авылдан бик күп укучылары да минем фикерне кабатларлар.

**- Венер абый, әтиегезнең һөнәрен сайларга уйламадыгызмы?**

- Юк шул, ул вакытта бу эшне бик яратканнар гына эшли алгандырмы, белмим. Бездә андый теләк булмады. Укытучыларның ул вакытта хезмәт хаклары бик түбән иде. Мин инде үз туган авылымда күмәк хуҗалыкта эшләүне теләдем. Гомерем буе тракторчы булып эшләдем.

**- Туган авылыгызда яшәүне бәхет санныйсызмы?**

- Туган ягыңда кирәкле һөнәрең белән эшләүдән дә зур бәхет юктыр ул. Иптәшем Флера апагыз, авылга иң беренчеләрдән дип әйтер идем, фельдшерлыкка укып кайтты. Бөтен гомерен авылыбыз халкын дәвалауга багышлады. Ул да эшен яратып, беркемгә каршы килмичә эшләде. Без беркайчан да тормышыбыздан зарланмадык, барына канәгать булып яшәдек.

**- Безнең мәктәп укучыларына нинди теләкләр әйтегез идегез?**

- Сезнең дә үрнәк алырлык укытучыларыгыз бар. Укытучы һөнәре беркайчан да бетмәс. Укытучылыкка укып туган авылларыгызга кайтыгыз. Авыл бетмәсен, балалар күп булсын өчен тырышып йөргән Рафик абыегыз кебек булыгыз.

**- Венер абый, Флера апа, әңгәмәгез өчен Сезгә бик зур рәхмәт. Сезгә бәхетле картлык көннәре теләп калабыз.**

*Әңгәмәне Сара Насыйрова, Алия Гыйзәтуллина һәм Рузилә Мөхәммәтова язып алдылар*

## /Истәлеккә – фотосурәт/



Бу фотосурәт 1960 еллар башында Югары Майна мәктәбендә төшерелгән. Беренче рәттә уртада – математика укытучысы Вәлиәхмәт абый Нигъмәтуллин. Укучылар арасында Түбән Майна балалары да, Югары Майнаныклар да бар.

Өлкән яшьтәге газета укучыларыбыздан фотодагы балалар турында мәгълүмат көтеп калабыз. Кем күбрәк кешене таный, шуңа редколлегия исеменнән бүләк булачак. Конкурс нәтиҗәләре газетаның киләсе санында чыгачак.

**/Җирем – суым/**



## *Күзге сәяхәт*

Укытучылар көне хөрмәтенә 6 октябрь көнне көзге табигать хозурына сәяхәт оештырылды. Сәяхәттә ветеран укытучылар Сәкинә һәм Ильһамия апалар да катнашты. Быел без Югары кырдагы Иске авыл зираты янындагы болынга бардык. Көн җилле булуга карамастан, барыбызның да кәефләре күтәренке иде. Сайлаган урынга җыелышып беткәч, Рафик абый бу урыннарның тарихы белән таныштырды. Аннан соң иске зират өстенә куелган истәлек ташы янында фотога төштек.

Кырга чыгуның күрке учак белән. Якындагы куаклыктан корыган агачлар ташып учакны кабызып җибәргәч, футбол уйнадык. Уйнап туйгач, учакта пешкән балык шулпасы һәм кыр җимешләреннән кайнаткан компот белән сыйландык. Туган якның алтын көзе барыбыз өчен дә якты бер истәлек булып калды..

***Рузилә Мөхәммәтова, 9 сыйныф укучысы***

---




**/Безнең уңышлар/**


19 октябрь көнне Чистай шәһәрендә Татарстан Республикасының атказанган укытучысы А.В.Шабаев истәлегенә 1- 4 сыйныф укучылары арасында республика шахмат турниры үтте. Әлеге турнир һәр сыйныф балалары арасында аерым үткәрелде. Һәр төркемдә 30лап бала катнашты. Аксубай районыннан да 4 укучы көч сынашты. Көрәш бик кызу иде. Соңгы минутка кадәр беркемнең дә бирешәсе килмәде. Ярышта безнең мәктәп укучылары Гафиятуллин Фаил һәм Хәйруллин Айназ да үз мөмкинлекләрен тикшереп карадылар. Нәтиҗәдә, Гафиятуллин Фаил 2009 - 2010 елгы укучылар арасында 2 урынга лаек булды. Ул грамота һәм акчалата приз белән бүләкләнде.

---


**/Күңелле тәнәфес/**



**Аклар башлап, 2 йөрештә мат куя**



**Аклар башлап, 3 йөрештә мат куя**



**Аклар башлап, 2 йөрештә мат куя**

---

Укытучы :

- Синең бу билгеләреңне күргәч, әтиеңнең чәчләре агарачак бит!
- Юк апа, агармаячак!
- Нишләп шулай дисең?
- Чөнки безнең әтинең башы пеләш!

---




**/Котлыйбыз!/**

Октябрь аенда туган көнен билгеләп үтүче **Камалова Сирин апаны** гомер бәйрәме белән котлыйбыз. Аңа гаилә бәхете, сәламәтлек, хезмәтендә уңышлар телибез.

Октябрь аенда туган балалар – бакча төркеменнән **Инсаф** белән **Гайшә**, III сыйныф укучысы **Хәнифә**, (5 октябрь), IV сыйныфтан **Ләйлә** (**Нургалиева**) (9 октябрь) , VI сыйныф укучылары **Рияз** (25 октябрь), **Әхмәт** (29 октябрь), VIII сыйныфтан **Данил** (24 октябрь), IX сыйныфтан **Халитны** (22 октябрь) туган көннәре белән котлыйбыз. Барыгызга да ныклы сәламәтлек, укуларыгызда зур уңышлар теләп калабыз.

**<u>Газетаны гамәлгә куючы</u> – Түбән Майна урта мәктәбе**

**<u>Мөхәррир</u> – Фәнүзә Гафиятуллина**

**<u>Редколлегия әгъзалары:</u>**

**Әминә Туктамышева**
**Виктория Нукина**
**Зөлфирә Сафиуллина**
**Алия Гыйззәтуллина**
**Нәзирә Әхмәтова**
**Рузилә Мөхәммәтова**
**Сара Насыйрова**